СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.02.2022 Әгерҗе шәһәре № 15-4

«2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау турында» 2016 елның 14 сентябрендәге 11-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау хакында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре торгларын үткәрмичә генә юридик затларга социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен арендага бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 09 июлендәге 554 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау турында» 2016 елның 14 сентябрендәге 11-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
«25» 02 2022 № 15-4
карары белән расланган

«2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау турында» 2016 елның 14 сентябрендәге 11-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр

2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе турында кушымтаның 3.2.3 пунктында "«Район буенча гамәлгә ашыруга планлаштырылган инвестиция проектлары «Стратегияне гамәлгә ашыру планына чаралар комплексы» 16 нчы таблицада китерелде" сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

Кадастр номерлары белән «Камада зур кемпинг» инвестиция проектын аның максатлары һәм җир кишәрлекләрендәге бурычлары нигезендә гамәлгә ашыру планлаштырыла:

1) 16:01:210304:38, гомуми мәйданы – 45267 кв. метр, рөхсәт ителгән файдалану төре - авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен, җирләрнең категориясе - авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир категориясе, адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Красный Бор авыл җирлеге;
2) 16:01:210304:39, гомуми мәйданы – 13376 кв. метр, рөхсәт ителгән файдалану төре - авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен, җирләрнең категориясе - авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир категориясе, адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Красный Бор авыл җирлеге;
3) 16:01:210304:40, гомуми мәйданы – 11841 кв. метр, рөхсәт ителгән файдалану төре - авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен, җирләрнең категориясе - авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир категориясе, адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Красный Бор авыл җирлеге;
4) 16:01:210101:92, гомуми мәйданы – 11468 кв. метр, рөхсәт ителгән файдалану төре - а/м транспорт һәм моторлы көймәләр кую урыны, торак пунктлар җирләре категориясе, адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Красный Бор авыл җирлеге, Красный Бор авылы;
5) 16:01:000000:2942, гомуми мәйданы - 19693 кв. метр, рөхсәт ителгән файдалану төре - гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре (территорияләр) өчен, торак пунктлар җирләре категориясе, адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Красный Бор авыл җирлеге, Красный Бор авылы;

6) 16:01:210101:86, гомуми мәйданы – 18754 кв. метр, рөхсәт ителгән файдалану төре - көймә станциясен төзекләндерү өчен, торак пунктлар җирләре категориясе, адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Красный Бор авылы, Ленин ур., 3 нче участок;
7) 16:01:000000:2958, гомуми мәйданы – 196138 кв. метр, рөхсәт ителгән файдалану төре - авыл хуҗалыгы өчен файдалану өчен, җирләрнең категориясе - авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир, адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Красный Бор авыл җирлеге;
8) 16:01:210304:11, гомуми мәйданы – 25728,3 кв. метр, рөхсәт ителгән куллану төре - билгеләнмәгән, җирләрнең категориясе - билгеләнмәгән, адресы - ЕЗП составындагы җир кишәрлеге;
9) 16:01:210304:10, гомуми мәйданы – 5544,21 кв. метр, рөхсәт ителгән куллану төре - билгеләнмәгән, җирләрнең категориясе - билгеләнмәгән, адресы - ЕЗП составындагы җир кишәрлеге;
10) 16:01:210304:2, гомуми мәйданы – 399376 кв. метр, рөхсәт ителгән куллану төре - билгеләнмәгән, җирләрнең категориясе - билгеләнмәгән, адресы - ЕЗП составындагы җир кишәрлеге;
11) 16:01:210304:9, гомуми мәйданы – 178977,48 кв. метр, рөхсәт ителгән куллану төре - билгеләнмәгән, җирләрнең категориясе - билгеләнмәгән, адресы - ЕЗП составындагы җир кишәрлеге;
12) 16:01:210304:42, гомуми мәйданы – 2215 кв. метр, рөхсәт ителгән файдалану төре - авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен, җирләрнең категориясе - авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир категориясе, адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Красный Бор авыл җирлеге;
13) 16:01:210304:41, гомуми мәйданы – 3748 кв. метр, рөхсәт ителгән файдалану төре - авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен, җирләрнең категориясе - авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир категориясе, адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Красный Бор авыл җирлеге;
14) 16:01:210101:96, гомуми мәйданы – 6000 кв. метр, рөхсәт ителгән файдалану төре - бушату-төяү эшләре өчен мәйданчык урнаштыру һәм оештыру өчен, торак пунктлар җирләре категориясе, адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Красный Бор авылы, Ленин ур., 3.

Инвестицион проектны гамәлгә ашыру кысаларында:

- күрсәтелгән җир кишәрлекләрен объектны урнаштыру өчен стратегик планлаштыру документларында билгеләнгән өстенлекләргә һәм максатларга туры китерергә;

- һәр җир кишәрлегенең бирелә торган мәйданының туры килүен билгеләргә, шулай ук аны «Камада Зур кемпинг» проектын гамәлгә ашыру өчен бирү мөмкинлеген тәэмин итәргә.

- җир кишәрлекләренең кадастр бәясен билгеләргә;

- күрсәтелгән җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану төре – туристларга хезмәт күрсәтү өчен (код ВРИ ЗУ 5.2.1), максаты-потенциаль инвесторлар өчен дип үзгәртү һәм күчерү эшен башкарырга